КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 февраль г.Казань № 85

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында» 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 82 нче, 2017 ел, 04 август, 552 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартына (алга таба – Стандарт) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эре, икътисадый һәм социаль әһәмиятле (система барлыкка китерүче) предприятиеләр һәм оешмалар исемлегенә керүче Оешмаларның үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы предприятиеләр һәм бюджет барлыкка китерүче предприятиеләрнең, шулай ук башка оешмаларның (шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларын да) Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар барлыкка килү сәбәпләрен ай саен карап тикшерү һәм Стандартка кушымта нигезендә формалар буенча  Оешмалар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә аларны түләү турында тәкъдимнәр әзерләү;»;

бишенче абзацта «алдагы ел» сүзләреннән соң «агымдагы ел дәвамында Оешмаларның финанс-икътисадый эшчәнлеге күрсәткечләрен, шул исәптән 30 процентган да күбрәк кимегү турында» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «табыш» сүзен «салым салуга кадәр һәм салым салына торган табышка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«табышка салым буенча квартал (еллык) хисапларын тапшырганнан соң, Комиссия утырышларында планлы-зыянга эшләүче Оешмаларны карау.»;

3.2 пунктның икенче абзацында «ай саен, 10 числога кадәр» сүзләрен «ай саен, 15 числога кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Министрлык оешмаларның мәгълүматларын квартал саен финанс нәтиҗәләре турында хисап нигезендә һәм ел саен бухгалтерлык балансы һәм Стандартка кушымта нигезендә формалар буенча бухгалтерлык балансына (еллык хисапны тапшырганда) кушымта нигезендә җыюны тәэмин итә.

Капиталның үзгәрешләре (еллык хисапны тапшырганда), акча хәрәкәте турында (еллык хисапны тапшырганда), акчадан максатчан файдалану турында (еллык хисапны тапшырганда) хисаплар Министрлык тарафыннан, җентекле аналитик хисап әзерләү зарурилыгы буенча, Оешмалардан соратып алына.»;

Стандартка кушымтаның «Салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар күрсәткечләре (ай саен тапшырыла)» 2 нче формасын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин